

Су тегермәне һәм “Тирмән алды” куаклыгы 1770 нче елгы картада.

**/ Чал тарихта эзле без /**

## Тирмән алды

Белгәнебезчә, авылдан көнбатыш яктагы болынлык **“Тирмән алды”** дип атала. Элек киек җәнлекләр дә адашырлык дәрәҗәдә куе булган бу куаклык, хәзер юкка чыгу алдында тора. Әле сугыштан чоргы елларда да Тирмән алдының куаклары хәзерге буа турысыннан башланып киткән. Анда куак-агачларның күп төрләре үсеп, җимеш бирә торган шомырт, карлыган, кура җиләге дә хисапсыз күп санда булган. Хәзер исә берән-сәрән үсеп утыручы карама һәм сазлыклардагы тал, зиректкән кала агач заты юк.

Тирмән алды куаклыгының бетүе турыдан-туры кеше эшчәнлегенә бәйле. Узган гасырның 50-60 нчы елларында колхозда һәм хуҗалыкта терлек саны арту сәбәпле, Тирмән алды җирләре көтүлек буларак файдаланыла башлый. Вак куакларны терлекләр ашап бетерсә, эре агачларның “башына” көтүчеләр җитә. Ул елларда утынга кытлык бик зур булганлыктан, көтүчеләр эре агачларның төбенә учак ягып, аларны корыткannар, ә корыган агачны утынга кисү гаеп эш саналмаган. Шулай итеп табигатьтәге тигезлек бозылган һәм бу калган агачларның да әкренләп бетүенә китергән. Мәсәлән, ачыклыкта калган шомырт агачларының күбесен күбәләк кортлары корытып бетерде. Әгәр бу шомыртлар куе булып, башка агачлар ышыгында үскән булсалар, мондый куркыныч аларга янамас иде.

Тирмән алдында төрле зурлыктагы өч исемсез күл бар. Алар яз көннәрендә Чирмешәннән ташыган сулар һәм кар сулары белән туенып торалар. Күлләрнең иң зуры камыш белән капланган һәм җәй урталарына тулысынча диярлек кибеп бетә. Калган ике күл бер-берсе белән тоташкан. Аларның төньяктагысы җәй башында ук кибә. Ә икенчесе, ел әйләнәсендә сулы булып торса да, 2010 нчы елгы корылыктан соң нык зәгыйфьләнеп калды.

“Тирмән алды” атамасының барлыкка килүенә су тегермәне сәбәпле. Әлеге тегермән башта Чирмешәннең хәзерге “Саржинат” куаклыгы башланган турысында урнашкан булган. Чирмешәннең суы саеккач, тегермән буасының субай калдыкларын әле соңгы елларда да күрергә мөмкин иде. Югары кырның Пәдер күле турысындагы тау битеннән тегермән буасы өчен кызыл балчык алынган урыннар да билгеле булып күренеп тора. XIX гасырның беренче яртысында бу тегермән авылга якынрак җиргә – хәзерге буадан түбәндәрәк урынга күчерелә. Авыл ягыннан караганда иске урынында да, яңасында да тегермән куаклыкның артында торган. Шул сәбәпле куаклык Тирмән алды дип аталган. Бу атама бабайлар хәзерге урынга күченгәннән соң, XVIII гасырның икенче яртысында кулланыла башлый. Чөнки иске авыл җиреннән караганда куаклык тегермәннең артында булып, “Тирмән арты” дип аталыр иде.



“Тирмән алды” 2000 нче еллар башында.

Тирмән алдының аланнары элек умарта тоту өчен файдаланылган һәм умартачыларның исемнәре белән атап йөртелгән. Моннан 10-15 еллар элек хуҗалыкның сыер көтүе табырлый торган култык, анда безнең Насыйр бабайның умарталары торганлыктан **“Насыйр бабай аланы”** дип аталган. Камышлы күлдән көнбатыш якта калку урында Туктамышев Хәйретдин бабайның умарталыгы торган һәм **“Хәйретдин бабай аланы”** дип йөртелгән. Чирмешәннең Насыйр бабай аланы турысына **“Ибрай тобасы”** дип аталучы урын бар. Бу атама Ибрай исемле малайның шул тобада балык тотарга йөргәнлегеннән калган диләр. 2000 нче елларга хәтле Ибрай тобасы кешене күмәрлек дәрәҗәдә тирән иде. Хәзерге вакытта Чирмешәннең башка урыннарыннан аермалы түгел.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***

**/ Котлыйбыз! /**



Җәй айларында туган көннәре булып узган балалар – бакча төркеменнән Сафиуллин Ислам белән Замалетдинов Фирдүсне, укучылардан Нургатин Фаил, Сафиуллина Гөлсем, Замалетдинов Зөлфәт, Сәгъдиев Рәмзис, Насыйрова Кәүсәр, Сафеева Настя, Гафиятуллин Фаил, Галиуллин Әхмәт, Нурматова Зәйнәп, Нурматов Мусаларны чын күңелдән тәбрик итәбез. Аларга тырыш, тәртипле, сәламәт булып үсүләрен телибез.

Мәктәп хезмәткәрләреннән тәрбияче Насыйрова Гөлүсә апаны, укытучылардан Гафиятуллина Руфия һәм Сафиуллина Алсу апаларны, пешекче Сабитова Илсөяр апаны гомер бәйрәмнәре белән котлап ныклы сәламәтлек, озын гомер, гаилә бәхете, җаваплы эшләрендә зур уңышларга ирешүләрен теләп калабыз.

**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:** Әминә Туктамышева, Виктория Нукина, Зөлфирә Сафиуллина

# Мәктәп хәбәрчесе

**№6**
(№47)
июнь-август
2023 ел

Түбән Майна урта мәктәбе гәзите

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru

**/ Безнең бәйрәмнәр /**

## Милли мәдәниятләр елында – балалар Сабантуе



2023 нче ел — Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителде. Татарстанда яшәүче һәр халыкның тарихи-мәдәни мирасы бик зур һәм бай. Гореф-гадәтләр, йолалар, бәйрәмнәр халык мәдәниятенең аерылгысыз бер өлеше булып тора. Алар тарихи үсеш барышында бик борынгы заманнарда ук халык тормышына үтеп кереп, милли яшәешнең аерылгысыз өлешенә әвереләләр. Аерым алганда, татар халкының милли бәйрәме Сабантуй халыкны милләт итеп берләштерә торган, аны дөньяга таныткан чараларның берсе булып тора.

Безнең мәктәптә даими рәвештә туган телне үстерү, балаларга милли гореф-гадәтләрне, төбәк тарихын җиткерү юнәлешендә максатчан эшчәнлек алып барыла. Шуның чагылышы буларак, уку елы тәгәлләнгәннән соң мәктәп коллективы тарафыннан балалар Сабантуе оештырылды. Балалар өчен аерым Сабантуй уздыру гадәте 2018 нче елдан башланып китте. Быелгы бәйрәм шундыйларның өченчесе булды. Мәктәп Сабантуйлары, башка бәйрәмнәр кебек үк, авылдашларны очраштыру, халыкның рухын күтәрү вазифасын үти. Бирегә бала-чага гына түгел, башка авылдашлар һәм читтән кайтучылар да җыела. Аерма бары тик шунда – төрле ярышларда бары тик балалар һәм яшүсмерләр генә катнаша.

4 нче июньнең кояшлы иртәсендә халык мәдәният йорты артына – Чирмешән буендагы матур болынга җыелды. Биредә алдан ук мәктәп хезмәткәрләре тарафыннан мәйдан әзерләнгән, чатыр корылган, укучылар ясаган күл эшләнмәләреннән, шамаилләрдән, нәсел шәҗәрәләреннән, музей экспонатларыннан күргәзмә оештырылган иде. Бәйрәм башлангыч һәм урта сыйныф укучыларының Сабантуй күренешләрен тасвирлаган җыр-биюле чыгышлары белән башланып китте. Бәйрәмнең тантаналы өлешендә мәктәп директоры Насыйров Рафик абый барча халыкны котлап, уку елын уңышлы тәгәлләгән һәм мәктәп тормышында актив катнашкан укучыларга мактау грамоталарын тапшырды. Аңардан соң сүз бәйрәмне котларга килгән мәртәбәле кунакларга бирелде. Аксубай районы мөхтәсибе, Татарстан дини идарә рәисе урынбасары Равил хәзрәт тәбрикләү сүзләрен җиткерде. Бу көнне Равил хәзрәтнең 50 яшьлек юбилее булганлыктан, Рафик абый аңарга Майна мәхәлләсе исеменнән бүләк итеп нәсел шәҗәрәләрен тапшырды. Аңардан соң бәйрәм котлавын Биләр урманчылыгы җитәкчесе Рамил абый Нуруллин җиткерде. Ул халык көче белән уздырыла торган шундый зур милли бәйрәмнәрнең тирә-яктагы авыллардан Түбән Майнада гына кала баруын билгеләп үтте.

Кисәктән генә килеп коеп киткән яңгыр Сабантуй барышына өзеклек кертсә дә, ул туктаганнан соң бәйрәм дәвам итте. Укучылар үзләренең әзерләгән чыгышларын оста итеп башкардылар. Аеруча икмәк үстерүнең барлык хезмәтләрен кхрсәткән тамаша Сабантуйның матур бер мизгеле булды. Бәйрәмне тәртипкә салып алып барырга X сыйныф укучылары Морадыймов Илсур белән Шичкина Карина зур өлеш керттеләр. Бәйрәмнең төрле ярышларында үзебезнең укучылар да, читтән кайткан балалар да актив катнашты. Барлык уен төрләрәнә бүләкләр тапшырылды. Бәйрәмдә катнашучылар Әнвәр абыйлары зур казанда пешергән пылау, мәктәп пешекчеләре әзерләгән коймак һәм чәй белән сыйландылар.

Сабан туеның төп чарасы – Милли көрәш. Ел дәвамында төрле дәрәҗәдә уздырылган ярышларда сынатмаган егетләребез авылыбыз бәйрәмен дә бизәделәр. Көрәштә Аксубай һәм Норлат районыннарының төрле авылларыннан килгән көрәшче егетләр дә катнашты. Көрәшчеләр 6 авырлык үлчәме буенча бүленеп, һәр төркемдә өчәр урын билгеләнде. Көрәш нәтиҗәләре буенча үзебезнең укучы Камалов Илдус батыр калып, төп бүләк – тәкәне алды. Калган көрәшчеләргә акчалата бүләкләр һәм грамоталар тапшырылды. Үзебезнең укучылардан Галимов Рияз, Замалетдинов Зөлфәт, Хәбибрахманов Абдулла, Сәгъдиев Рәмзисләр үз авырлыкларында төрле урыннар алуга ирештеләр.

Әлбәттә инде, шундый зур бәйрәмне матди чыгымнарсыз гына уздыру мөмкин түгел. Әле бәйрәмгә ике көн кала мәктәп лагерында ял итүче балалар авыл буйлап йөреп Сабантуй бирнәсе җыйганнар иде. Төп бүләк булган тәкәне садака итеп Габдуллин Әсхәт абыйдан алдык. Болардан тыш мәчеттән, җирле идарәдән, Аксу-Агро оешмасыннан, һәм авылдаш егетләр Хәйруллин Назыйф белән Хәтметдинов Раилдән бишәр мең сум акчалата ярдәм алынды. Аларның барысына да мәктәп коллективы исеменнән олы рәхмәтебезне җиткерәбез.

***Фәнүзә Гафиятуллина, баш мөхәррир***

## Дәүләт йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре

**/ Рәсми хәбәрләр /**

**IX сыйныфларның имтихан билгеләре**

| Укучылар | Математика | Рус теле | Татар теле | География | Информатика | Биология |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Галимов Рияз | 4 | 3 | 5 | 4 | - | - |
| Гафиятуллин Самат | 4 | 5 | 4 | 4 | - | - |
| Залиев Салават | 3 | 3 | 4 | - | 3 | - |
| Замалетдинова Инзилә | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - |
| Нурматова Зәйнәп | 4 | 4 | 5 | 4 | - | - |
| Хабибрахманов Әхмәт | 3 | 3 | 3 | - | 4 | - |
| Хабибрахманова Мәрьям | 4 | 4 | 5 | - | - | 4 |
| Сыйныф буенча | 3,7 | 3,7 | 4,3 | 4 | 3,5 | 4 |

**XI сыйныфларның имтихан билгеләре һәм баллары**

| Укучылар | Математика (база) | Математика (профиль) | Рус теле | Җәмгыять белеме | Химия | Биология |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Камалов Илдус | 5 | - | 55 | - | - | 45 |
| Нукина Вика | 5 | - | 72 | 49 | - | 42 |
| Сафиуллина Зөлфирә | - | 58 | 72 | 55 | 65 | - |
| Туктамышева Әминә | 5 | - | 66 | - | 70 | 57 |
| Сыйныф буенча | 5 | 58 | 66 | 52 | 67,5 | 48 |

Быелгы уку елын XI сыйныфны тәмамлаган 4 укучының барысы да югары уку йортларына керү бәхетенә ирештеләр. Камалов Илдус Идел буе спорт һәм туризм академиясендә (КФУ) укуын дәвам итәчәк. Нукина Вика КФУның биология һәм инглиз теле укытучысы факультетында, Сафиуллина Зөлфирә КНИТУда азык-төлек һәм биотехнология бүлегендә, ә Туктамышева Әминә КФУда экология бүлегендә белем алуларын дәвам итәчәкләр.

IX сыйныфны тәмамлаган 7 укучының 5 се төрле һөнәр алу көллиятләренә урнаштылар. Галимов Рияз Яр Чаллы шәһәренең ГАПОУ да эретеп ябыштыручы, Замалетдинова Инзилә Түбән Кама шәһәрендә күп профильле көллияттә пешекче, Залиев Салават Аксубай техникумында автомеханик, Хәбибрахманов Әхмәд белән Хәбибрахманова Мәрьям Түбән Кама педагогия көллиятендә физкультура укытучысы һәм башлангыч сыйныфлар укытучысы һөнәрләрен үзләштерәчәкләр

***Илдар Сафиуллин, укыту эшләре буенча директор урынбасары***

## Мәктәпне яңа уку елына әзерләү эшләре




Һәр елдагыча, җәйге айлар мәктәпне яңа уку елына әзерләү чаралары белән үтә. Быелгы уку елы безнең өчен зур яңалык – мәктәбебезнең **"Үсеш ноктасы" ("Точка роста")** федераль белем бирү үзәкләре челтәренә кертелүе. (Әлеге проект турында алдагы санда тулырак мәгълүмат бирелер) Шушы проектны тормышка ашыру максатыннан, мәктәптә табигать фәннәре – физика, химия һәм биология кабинетлары тиешле таләпләргә туры китерелеп ремонтланды. Ул фәннәр буенча лаборатория җиһазлары һәм оргтехника кайтарылды. Аларны дәресләрдә һәм өстәмә белем бирү чараларында куллану каралган.

Яңа уку елына әзерлек буенча икенче зур яңалык – мәктәпне тавыш белән хәбәр итү системасы белән җиһазландыру. Әлеге чара беренче чиратта мәктәп укучылары һәм хезмәткәрләренең иминлеген тәэмин итү өчен кирәк. Аның төп вазифасы – янгын, авария, һөҗүм итү куркынычы кебек хәвеф-хәтәр булган очракларда тиз арада хәбәр бирү. Шулай ук бу җайланма мәктәп буенча игъланнар һәм башка кирәкле хәбәрләрне тапшыру өчен отышлы. Хәзер вахтадан яисә завуч кабинетыннан торып, мәктәпнең барлык кабинетларына һәм бүлмәләренә хәбәр ирештерү мөмкинлеге бар.

***Рафик Насыйров, мәктәп директоры***



## Шәкүровлар гаиләсенең балалар бакчасына бүләге

Безнең бакча төркемендә балаларга тәрбия һәм белем бирү өчен күп уңайлыклар бар. Шуларга өстәлеп тагын бер зур мөмкинлеккә ия булдык. Чаллы шәһәрендә яшәүче Ингел һәм Рәзинә Шәкүровлар гаиләсе безнең бакча балаларына бик матур курчак өе бүләк итте. Ике катлы, баскычы һәм шуа торган таучыгы булган бу өйдә балаларыбыз бик яратып уйныйлар. Авылыбызга күрсәткән ярдәмнәре өчен аларга балалар Сабантуенда мәктәпнең Рәхмәт хаты тапшырылды. Шундый зур бүләк белән сабыйларны шатландырганнары өчен Ингел абый белән Рәзинә апага үзебезнең олы рәхмәтләребезне җиткерәсебез килә.

***Гөлүсә Насыйрова, бакча төркеме тәрбиячесе***

**/ Безнең бәйрәмнәр /**



## Балаларга корбан бәйрәме

Без гает бәйрәмнәрен яратабыз. Әле кайчан гына Ураза гаетендә "тәмле" бәйрәм оештырган иде. Инде менә Корбан гаете дә килеп җитте. Бу бәйрәм хөрмәтенә авылыбыз балаларына матур гына сый-хөрмәтле бәйрәм уздырылды. Өченче июль кичендә без авылыбызның иң карт агачы төбенә җыелыштык. Без килгәндә Илдар абый һәм башка укытучылар корбан итеннән шулпа белән шашлык әзерлиләр иде инде. Балалар җыелышып беткәч иң элек башлангыч сыйныф укытучылары мавыктыргыч эстафеталар оештырды. Безнең белән бергә авылга кунакка кайтучы балалар да рәхәтләнеп ял итте. Ул арада гает ашлары да пешеп җитте. Яшел чирәмгә җәелгән табын төрле җиләк-җимеш һәм тәм-томнар белән тулган иде. Ашап туйгач безне Динә апа дини эчтәлекле уен уйнатты. Балалар бәйрәме өчен Корбан итеннән өлеш чыгарган авылдашларга бик зур рәхмәт. Безнең кебек бәхетле мәктәп балалары тагын кайда бар икән?!

***Айназ Хәйруллин, VIII сыйныф укучысы***

## Күңелле лагерь

**/ Мәктәп тормышы /**

Мин җәйге каникулны һәр елны көтеп алам. Чөнки каникул көннәрендә безнең өчен бик күңелле җәйге лагерь була. Быелгы лагерь беренче июнь көнне башланып китте. Беренче көннәрне без мәктәп Сабантуена әзерләндек. Калган көннәрне күңелле уеннар уйнап, тәмле ашап ял иттек.

Башка еллардагы кебек үк быелгы лагерьда да төрле сәяхәтләргә йөрдек. Иң беренче без Казан шәһәренә экскурсиягә бардык. Казанга барып җитүгә шәһәрнең күрке булган Кремль бүйларында йөредек. Әйләнә-тирә дөнья дәресләрендә үткән темаларны ныгытыр өчен апаларыбыз музейга алып керделәр. Аннан чыгып, Авыл хуҗалыгы сараенда төшке ашны ашаганнан, соң циркка юнәлдек. Анда әле күбебезнең беренче тапкыр баруы иде. Казанда булган һәр минут бик кызыклы үтте.







Сәяхәтләребез Казан белән генә чикләнмәде. Чирмешәннең биек яр буйларын карарга, Аксубай бассейнда коенырга барырга да өлгердек. Биләрдәге Страус фермасына да барып, әллә нинди төрле киек җанварларны күреп, сәенеп кайттык. Авылыбыз чишмәсе Чәчәбигә барганда пешекче апаларыбыз бүргер ясарга барлык ризыкларны әзерләп бирделәр.

Ял иткән вакытыбызда бер генә истәлекле көнне дә билгеләмичә калдырмадык. 22 нче июнь – сугыш башланган көнне искә алып, һәйкәлгә чәчәкләр куйдык. Лагерьда эшләгән апалар да без файдалы, кызыклы ял итсеннәр өчен барысын да эшләделәр. Аларга бик зур рәхмәт.

***Ләйсән Закирова, V сыйныф укучысы***

**/Безнең спорт/**



Июнь ае көрәшче егетләребез өчен "урак өсте" булды. Аксубай Сабан туенда Камалов Илдус яшьләр арасында беренче урын һәм тәкәне алды, зурлар арасында 70 кг га кадәр 1нче урынга ия булды. 25 кг га кадәргеләр арасында Замалетдинов Зөлфәт, 35 кг га кадәргеләрдә Хәбибрахманов Абдулла, 60 кг га кадәргеләрдә Галимов Рияз 1 нче урыннарны яуладылар. Шичкин Али 45 кг га кадәр авырлыкта 2 нче урынны алуга иреште.

18 нче июнь көнне Яр Чаллы шәһәре Сабантуенда Камалов Илдус үз авырлыгында III урынны алды.

24 нче июньда Ульян өлкәсе Мәләкәс (Дмитровград) шәһәре Сабантуенда үз авырлыкларында Замалетдинов Зөлфәт белән Галимов Рияз 2 нче урыннарны, Камалов Илдус беренчелекне алды. Шулай ук ир-атлар арасындагы көрәштә Илдус 2 нче урынны яулады. Батырларга ныклы сәламәтлек һәм яңа җиңүләр телибез**.**